**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге Бахтачы торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“29” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Бахтачы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Бахтачы торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, Бахтачы авылына юлны ремонтлау, вак таш сатып алу һәм салу, эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)

2)Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын һәм яктырткычлар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү)

3) Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (зиратны койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм хезмәт өчен түләү) »

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бахтачы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Утырыш рәисе,
Күлле-Киме авыл җирлеге Советы
2 нче сайлау округы депутаты Сабиров Ф.Р.